**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**муниципального**
**образования « Масягутовского**
**сельского поселения»**
ул. Дружба д.12
с. Масягутово, Азнакаевский район, 423311
Тел ( Факс) : (8 – 85592) 38-2-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**“ Мәсгут авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**
Дружба урамы, йорт12, Мэсгут авылы,
Азнакай районы,423321
Тел(факс) :(8 –85592) 38-2-16

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» ноябрь 2020 ел № 22

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 21 ноябренә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауларны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум куләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Мәсгут авылы 1 Май, 8 Март урамнары буенча юлларны вак таш һәм гравий белән төзекләндеру;
- Мәсгут авылы зиратын коймалау;
- Мәсгут авылында юлларны кардан чистарту;
- урамнарны яктырту өчен электр товарлары сатып алу;

- үзәкләштерелгән чыганактан эчә торган суны анализлау;
- Бәйрәм чараларын оештыру Һәм уткәру (Яна ел, Җиңу көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне)

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык:




Э.Ә.Габдрахманов